



*Куәм урта гомуми белем мәктәбе газетасы* *№5 Январь, 2026 ел*



**Татарстанда 2026 ел Хәрби һәм хезмәт батырлыгы елы дип игълан ителде. Бу хакта Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов ТР Дәүләт Советына еллык юлламасы белән чыгышында әйтте. Ул бүген ил сакчыларына игътибарлы караш, патриотик проектларны тормышка ашыру әһәмиятен билгеләп үтте.Рөстәм Миңнеханов быел Бөек Җиңүнең 80 еллыгы билгеләп үтелгәнен искәртте.**

## Ветеран укытучылар белән танышуны дәвам итәбез



**Батталова Нурания**

1943 нче елның 19 февралендә Куәм авылында колхозчы гаиләсендә туа. 1 нче сыйныфка да шунда бара. Беренче укытучысы Сибгатуллина Кәшифә апа була. Куәм мәктәбендә 7 нче сыйныфны тәмамлаганнан соң, урта белем алу теләге белән, Олы Әтнә урта мәктәбенә юл тота. 1962 нче елда югары белем алу теләге Казанга алып килә. КДПИ ның татар теле бүлегенә укырга керә. 1965 елда Кече Әтнә сигезьеллык мәктәбенә татар теле һәм әдәбияты укытучысы кирәк була. 3 нче курсны тәмамлаган Нурания Бакый кызы шунда кайта. 5 ел балаларга бик тырышып татар теле һәм әдәбияты укыта. Әмма 1969 елда Кече Әтнә мәктәбе башлангыч мәктәп булып кала. Нурания ханым туган мәктәбенә кайта. Монд аңа 31 балалы 1 нче сыйныф укучыларын тапшыралар. Аларны 1 ел гына укытып кала. 1970 елда аңа тарих һәм музыка дәресләре бирәләр, 5 нче сыйныфларнын класс җитәкчесе вазыйфасын да башкара. Шул вакыттан башлап ул тарих укытучысы булып кала, соңрак җәмгыять белеме фәннәре дә өстәлә. Кабинетында музей ача. Бөртекләп бик күп әйбер җыйган идем, дип искә ала.

1998 елда лаеклы ялга чыккан. 34 еллык эш стажы бар. Аллага шөкер, ветеран труда бирделәр, дип шатлана.

**Грамоталары:**

Яшь буынны укыту һәм тәрбияләүдә озак еллар нәтиҗәле эшләве һәм 55 яшь тулу уңае белән ТР мәгариф министрлыгының мактау грамотасы белән бүләкләнә (13.02.1998)

Почетная грамота . Арский РОНО и райком профсоюза работников просвещения награждают Батталову Нуранию Бакиевну – учительницу истории Кубянской средней школы Арского района ТАССР за успехи в обучении и коммунистическом воспитании учащихся.

## Мәктәбебездә Яңа ел бәйрәме



Яңа ел һәр кешенең дә зарыгып көтеп алган бәйрәмнәренең берсе.Безнең мәктәбебездә дә Яңа ел бәйрәме күңелле узды.

Без, 2нче сыйныф укучылары, бәйрәмгә бик җаваплы әзерләндек.Иң элек сыйныф бүлмәбезне бизәдек.Сыйныф бизәү буенча мәктәп күләмендә 2нче урынны яуладык.Аннары без бик күп концерт номерлары өйрәндек,шигырьләр ятладык.

Бәйрәм буласы залда түрдә хуш исле чыршы балкып торды.Ә кунак булып Кыш бабай белән Кар кызы килде.Алар һәр балага конфетлар , укуыбызда уңышлар, сәламәтлек теләде.Без Кыш бабайга үзебезнең осталыкларыбызны күрсәттек.Бәйрәм җыр-биюле,күңелле күренешләр белән үрелеп барды.

Миңа бәйрәм бик ошады.Килгән кунакларыбыз да,әти-әниләр дә бәйрәмне сокланып карап утырды.Шундый матур бәйрәм әзерләгән укытучы апаларыбызга зур рәхмәт!

Яңа ел безгә бары тик яхшы хәбәрләр, уңышлар гына алып килсен.Дөньяларыбыз тыныч эшләребез уң,укуыбызда гел яхшы билгеләр генә булсын,барыбыз да сәламәт булыйк!

**Харасов Дамир, 2 нче сыйныф укучысы**

## Кыш бабай бүләкләре



Без быел беренче тапкыр мәктәптә Кыш бабай белән Кар кызын каршы алдык. Алар килгәнне зур түземсезлек белән көттек, әниләребез ярдәме белән матур итеп сыйныф бүлмәбезне бизәдек, шигырьләр, җырлар өйрәндек.

Менә ул көн килеп җитте. Кыш бабай белән Кар кызы безгә күп итеп тәмле- тәмле бүләкләр алып килгән иде. Аларга бик зур рәхмәт.

**1 нче сыйныф укучылары.**

## Минем кышкы ялым.

Менә Яңа ел бәйрәмнәре дә килеп житте. Кыш бабай безгә тәмледән тәмле күчтәнәчләрен алып килде. Мәктәптә яңа ел бәйрәме уздырганнан соң, безнең кышкы каникуллар башланып китте.

Каникулда мин Гөлия апаем белән Казан шәһәренә бардым. Ул мине узе белән Кәрим Тинчурин театрына алып килде. Алар анда спекталь карарга килгән балаларга төрле уеннар уйнаттылар, аларда миндә катнаштым. Мина бик ошады. Соңыннан апам мине театрның олы сәхнәсенә дә алып чыкты. Сәхнәдән актерга куренгән залнын матурлыгы, аның зурлыгы мине шаккаттырды.

Кич белән Юртага бардык, анда Борыңгы төрекләр спектакле карадык. Спектакльга килгән кунакларны чәй һәм чәк - чәк , Башкортстаннан кайткан казылык белән сыйладылар. Мина анда бик ошады. Мин хәтта Коктель кочевника – кумыз эчеп карадым. Икенче көнне без Гөлия апам белән кинотеатрга барып, “Чебурашка 2” дип исемләнгән гаилә мультфильмын карадык. Аннан соң “Кыстыбый” кафесына кереп тәмләп ашадык.

Икенче көнне авылга кайтып киттек. Авылга кайткач, мин чаңгыда , тимер аякта шудым. Китаплар укып, рәсемнәр ясадым. Миңа быелгы каникул бик ошады. Туземсезлек белән язгысын көтәм.

**Калимуллина Гүзәл, 5 нче сыйныф укучысы**



## Кышкы каникул хикмәтләре

Без 3 нче сыйныф укучылары туган илебезне саклаучы солдат абыйларыбызга хатлар яздык.

Кадерле, солдат абый! Рәхмәт сиңа, мең-мең рәхмәт! Мин сокланам һәм горурланам синең белән. Сезнең хәрби хезмәтегез жиңел түгел. Шуна да карамастан сезгә көчле һәм нык булырга туры килә. Сез анда сакта торганда, без якты зур мәктәпләрдә белем алабыз. Сез безнең тынычлыкны саклыйсыз.Сезнең һәрберегез безгә якын һәм кадерле.Сезгә мең-мең рәхмәт.Исән сау туган илләрегезгә әйләнеп кайтыгыз.

**Ахметшин Ильмир, 3 нче сыйныф укучысы**

## Көмеш кыш
## (экият)

Борын-борын заманда, ерак бер урманда Кыш бабай яшәгән. Бервакыт ул урманга көмеш кар яудырырга уйлаган. Ул сызгырып җибәргән, һәм күктән меңләгән кар бөртеге биеп төшә башлаган.

Урмандагы җәнлекләр бу матурлыкка бик куанганнар. Куяннар ап-ак туннарын кигәннәр, ә тиеннәр үзләренең җылы ояларына качканнар. Шулвакыт кечкенә бер чыпчык туңып калган. Кыш бабай моны күргәч, аңа җылы җил өргән һәм канатларын көмеш нурлар белән бизәгән. Чыпчык канатларын кагып, шатланып сайрый башлаган.

Шул көннән башлап, бу урманда кыш һәрвакыт тылсымлы һәм күңелле үтә икән. Карлар кояшта бриллиант кебек җемелди, ә җәнлекләр Кыш бабайның бүләкләренә шатланалар.

**Мөхәммәтшин Зөлфәт, 10 нчы сыйныф укучысы**

## Атналык кызыклы үтте

Без мәктәптә үткәрелгән табигать фәннәре атналыгында катнаштык. Биология химия укытучысы һәм сыйныф җитәкчесе Ганиева Ләйсән Фәргать кызы белән табигать һәм әйләнә - тирә турында төрле әңгәмәләр уздырдык. Барлык чараларда катнаштык. Матур пөхтә дәфтәрләр күргәзмәсенә аерым укучыларның эш дәфтәрләре куелды. Кул эшләре күргәзмәсенә төрле эшләнмәләр һәм макетлар куелды. Кул астында булган гади генә әйберләрдән эшләдек, кызыл китапка кергән төрләрне искә төшердек. Юсупов Рөстәм, Бариева Зилия эшләре күргәзмәдә аерым урын алды. Шулай ук 5-7 сыйныфлар эшләгән рәсемнәрдән рәсем күргәзмәсе куелды. Күп төрле темаларга укучылар төзегән кроссвордлар тәкъдим ителде. 20 нче гыйнвар көнне 5нче һәм 6нчы сыйныф укучылары арасында “Үсемлекләр дөньясында” дигән викторина булып узды. Табышмаклы сораулар, биремнәр һәм рәсемнәр буенча яңа белемнәр алдык. Табигать фәннәренең күп төрлелеге, андагы күп организмнарның үзара бәйләнешләре белән таныштык. Кулланган батареяларны да ташларга ярамый. Презентация буенча нәтиҗәләр ясадык. Презентация белән безне , 21нче гыйнвар көнне 9 сыйныф укучылары таныштырды. Кулланган батареяларны аерым пунктларга тапшырырга кирәк. Зыяны кешеләргә, табигатькә, сулыкларга бик зур. Атналык кысаларында экологик белемнәрне ныгыттык, әйләнә - тирә табигаткә сак караш формалаштыру кирәклеген белдек. Әйләнә- тирәдә, көндәлек көнкүреш тормышта химик матдәләр дә киң кулланыла. Дарулар, юучы матдәләр, ягулык төрләре, ашламалар һәм башкалар бик киң таралган. Бу матдәләрне дә дөрес итеп куллана белү мөһим. “Химия әйләнә тирәдә” дигән тема астында телдән журналда чыгыш ясадык.

**Хадиева Иделия, 6 нчы сыйныф укучысы**


## Гыйнвар аена сынамышлар һәм ышанулар

Гыйнвар – елның иң салкын ае, кыш түбәсе. «Җылы гыйнвардан Аллаһ сакласын», – дигәннәр. Бу аңлашыла да, җылы һәм кар әз икән, димәк, мул уңыш көтмә. Әмма салкын гыйнварлар рәттән кабатланмый. Әгәр бу ай узган ел җылы булган икән, быел суык киләчәк. Гыйнварда якты көн 1,5 сәгатькә озыная.

## Табигатьне саклыйк

Бар кеше дә табигатьне
Бик матур һәм саф , диләр.
Нигә соң шул матурлыкны
Саклап кала алмыйлар?
Ял итәргә аланлыкка
Гаилә белән чыгалар.
Саф һавада ял иткәч тә
Чүпләрне калдыралар.
“Табигатьне саклагыз», - дип
Бик күп җирдә язылган.
Табигатьнең чисталыгы
Безнең кулларда, дуслар.

**Юсупова Динә, 4 нче сыйныф укучысы**



## Дәреслекләрне саклыйк!

Укучының күңел көзгесе – китап. Унбер ел уку дәвамында укучы бик күп дәреслекләр белән таныша. Һәр елны яңадан-яңа дәреслекләр куллана, андагы белемнәрне үзләштерә. Дәреслекләрне китапханәдән алгач, аларны тышлап куярга кирәк, чөнки бер дәреслек белән укучылар берничә ел файдалана. Гомумән, китапханәдән алган бөтен китапларны саклап, кадерләп тотарга кирәк. Аларны ертмаска, бөкләмәскә, тапламаска, битләренә ручка яки карандашлар белән язмаска кирәк. Әгәр кайда калганыңны тиз генә табасың килсә, китап кыстыргычларыннан файдалана аласың. Аларны үзең дә ясарга мөмкин. Китап белем чишмәсе икәнен онытырга ярамый. Китапларга бик сак карыйк, укучылар!

**Шигапова Диләрә, 7 нче сыйныф укучысы**

## Саф һава – тәнгә дәва



Сагынып көткән кыш килеп житте. Без саф һавада төрле уеннар уйныйбыз, чөнки хәрәкәт сәламәтлек өчен файдалы.

Бүген без беренче тапкыр чаңгы шуарга чыктык. Апабыз безгә чаңгыларны дөрес итеп тотарга, кияргә, кардан чистартырга кирәклеген аңлатты. Беренче тапкыр чаңгыда шуу бик авыр да, күңелле дә булды. Без егылдык та, чаңгыны да, таякны да, хәтта бияләйне дә югалттык. Әмма барыбыз да бик шат иде.

**1 нче сыйныф укучылары**

- Чәүкә һәм каргалар һавада очып әйләнсә – кар явар, карга утырсалар – жылыга, агачларның өске өлешенә кунсалар – каты суыкларга;
- Чыпчыклар чыркылдашса – җепшетә;
- Гыйнварда тукран шакылдата башласа – яз вакытыннан алда килә;
- Елның беренче ае жылы икән, яз соңара һәм май суык була;
- Ел башы суык булса, җәй эссе килә;
- Гыйнвар кар-буранлы булса, җәй көне яңгыр еш явар;
- Гыйнварның икенче яртысында кояшлы көннәр – яхшы уңышка;
- Гыйнварда озын һәм еш урнашкан боз сөңгеләре эленеп торса, уңыш яхшы булыр;
- Сукыр тычкан гыйнварда оясыннан чыкса – май салкын була;
- Гыйнварда март булса, мартта гыйнвардан курык.

**Ганиева Дилә, 11 нче сыйныф укучысы**

## Игелекле эшләр кылыйк....

Мәктәбебездә игелекле эшләр башкарылды: укучылар һәм укытучылар ярдәме белән җыелган кирәк- яракларны беренчеләр хәрәкәте активистлары этләр приютына тапшырдылар. Әлеге изге гамәл һәрберебезгә мәрхәмәтлелекнең, җаваплылыкның никадәр мөһим булуын тагын бер кат искәртте. Приюттагы этләр тыныч, ягымлы булып, кешеләргә ышаныч белән карый иде. Бу очрашу безнең күңелендә тирән эз калдырды, яхшылык эшләү теләге уятты.
Килчәктә дә ярдәмгә мохтаҗларга битараф калмыйк. Чөнки безнең ярдәмгә кешеләр генә түгел, ә кече туганнарыбыз — хайваннар да мохтаж. Бердәм булганда гына без дөньяны тагын да матуррак итә алабыз. Барыгызга да зур рәхмәт.




## Гәҗитне басмага әзерләделәр

**Баш мөхәррир: Сөнгатова Г.З.**
**8 нче сыйныф укучысы :Шакирова Камилә.**
**6 нчы сыйныф укучысы: Галявиева Алия.**
**10 нчы сыйныф укучысы:Гатауллина Илүзә.**